# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Маҗын авыл җирлегенең Холодный Ключ торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

21 ноябрь 2025 № 2

2025 елның 20 мартында кабул ителгән № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче һәм 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Иске Маҗын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Маҗын авыл җирлеге Холодный Ключ торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Маҗын авыл җирлеге Холодный Ключ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Холодный Ключ торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (асфальт валчыклары сатып алу, ташу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны Иске Маҗын авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Иске Маҗын авыл җирлеге башлыгы Э.Р. Шәймәрданов